| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2020 елның 15 декабре № 4/2

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы бюджеты турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 һәм 92 статьялары нигезендә, Чүпрәле муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

**«1 статья**

1. 2021 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 690711,41 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 690711,41 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты кытлыгы юк.

2. 2022 һәм 2023 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2022 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 696942,31 мең сум һәм 2023 елга 701302,26 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2022 елга 696942,31 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 12217,23 мең сум күләмендә һәм 2023 елга 701302,26 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 24670,13 мең сум күләмендә;

3) Чүпрәле муниципаль районының 2022 елга һәм 2023 елга бюджет кытлыгы юк.

3. 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә билгеләргә.

**2 статья**

1. 2022 елның 1 гыйнварына Чүпрәле муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән Чүпрәле муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген нуленче мәгънәсе белән Россия Федерациясе валютасында расларга.

2. 2023 елның 1 гыйнварына Чүпрәле муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән Чүпрәле муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген нуленче мәгънәсе белән Россия Федерациясе валютасында расларга.

3. 2024 елның 1 гыйнварына Чүпрәле муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән Чүпрәле муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиген нуленче мәгънәгә ия Россия Федерациясе валютасында расларга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетында 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының фаразланган керемнәрнең күләмен әлеге Карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

2021-2023 елларда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетына күчерелү Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 2020 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган муниципаль унитар предприятиеләре табышының бер өлешенә 2021 елның 1 июленә кадәр чиста табышның 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

**5 статья**

1. «Чүпрәле муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары исемлеге» һәм «Чүпрәле муниципаль районы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары – Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеге» н әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**6 статья**

1. Бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына бүлүне әлеге Карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә расларга.

3. Бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына юнәлешләре (Чүпрәле муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Карарның 7 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. 2021 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 4815 мең сум, 2022 елга 4906 мең сум һәм 2023 елга 5004 мең сум күләмендә расларга.

**7 статья**

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен әлеге Карарның 8 нчы кушымтасы нигезендә расларга:

2021 елга - 44899,1 мең сум.

2022 елга - 44985,5 мең сум.

2023 елга - 45084,5 мең сум.

**8 статья**

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр күләмен әлеге Карарның 9 нчы кушымтасы нигезендә расларга:

2021 елга - 2049,0 мең сум.

2022 елга - 2070,8 мең сум.

2023 елга - 2154,6 мең сум.

**9 статья**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетында 2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны 532200,31 мең сум, 2022 елда 531213,01 мең сум, 2023 елда 528113,91 мең сум күләмендә әлеге Карарның 10 нчы кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**10 статья**

2021 елга Чүпрәле муниципаль районы Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 15600 мең сум, 2022 елга 16500 мең сум, 2023 елга 16500 мең сум күләмендә расларга һәм аларны Чүпрәле муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында 2021-2023 елларга юл эшләре программасы чараларын тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**11 статья**

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2021-2023 елларда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.
2. Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына 2021-2023 елларда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**12 статья**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты акчаларының 2021 елның 1 гыйнварына калган калдыкларын Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы исеменнән 2020 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүгә контрактлар төзү өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2021 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**13 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетын үтәүне, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә авыл җирлекләре бюджетларын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**14 статья**

Әлеге Карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**15 статья**

Әлеге карарны «Туган як» газетасында бастырырга. ».

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров